| БАВЛИНСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ |
|---|---|

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25.05.2023 Баулы шәһәре №97

Җирле салымнар суммалары өлешендә
бурычны түләтү өметсез дип тануның өстәмә
нигезләрен билгеләү турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, Баулы шәһәр Советы карар итте:

1. Җирле салымнар суммалары өлешендә бурычны түләтү өметсез дип тануның түбәндәге өстәмә нигезләрен билгеләргә:

1) физик затның үлеменнән яки аны, граждан-процессуаль законнарында билгеләнгән тәртиптә, вафат булган дип таныганнан соң, әгәр закон буенча да, васыять буенча да булмаса, я варисларның берсе дә мираска хокукка ия булмаса яки барлык варислары да мирастан читләштерелсә, йә мирасны берәү дә кабул итмәсә, йә барлык варислар мирастан баш тартса, шул ук вакытта аларның берсе дә башка варис файдасына баш тартуын күрсәтмәсә;

2) салым түләүченең - физик затның гражданнарга стационар социаль хезмәт күрсәтүне гамәлгә ашыручы оешмада булуы;

3) юкка чыгарылган җирле салымнарны түләү бурычы барлыкка килгән көннән соң өч ел вакыт узу;

4) салым салу объекты булган мөлкәткә милек хокукы туктатылган көннән соң өч еллык срок узу;

5) бурыч барлыкка килүдән өч елдан артык вакыт узуны күрсәтүче даталы түләтү мөмкинлеге булмау турында акт булу;

6) «Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 02 октябрендәге 229-ФЗ

номерлы Федераль законның 47 статьясы нигезендә башкарма производствоны тәмамлау турында суд приставлары тарафыннан карар чыгару;

7) салым түләүченең - физик затның иректән мәхрүм итү урыннарында булуы;

8) 2006 елның 1 гыйнварына кадәр барлыкка килгән җирле салымнар буенча бурыч булу.

2. Үз көчен югалткан дип таныrга:

«Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының «Җирле салымнар, шушы салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычны түләтү өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында» 2014 елның 19 маендагы 94 номерлы карарын;

«Баулы шәһәре» муниципаль берәмлеге Советының «Җирле салымнар буенча недоимканы, әлеге салымнар буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурычны түләтү өметсез дип тануның өстәмә нигезләре турында» 2014 елның 19 маендагы 94 номерлы Баулы шәһәр Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы 2017 елның 16 августындагы 56 номерлы карарын.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Баулы муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карар 2023 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла һәм рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Баулы шәһәр Советының икътисадый үсеш, эшкуарлык, кече бизнес һәм торак-коммуналь хуҗалык мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Баулы шәһәре Мэры,
шәһәр Советы рәисе — И.И. Гозәеров